КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 22 сентябрь г.Казань № 1177

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында электр автомобиль транспорты өчен заряд җыю инфраструктурасын үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2022 ел, 7 июнь, 538 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1.Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында электр автомобиль транспорты өчен заряд җыю инфраструктурасын үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2022 ел, 7 июнь, 538 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 13 декабрь, 1320 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктта «Программа» сүзен «дәүләт программасы» сүзләренә алмаштырырга;

2 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«дәүләт программасының җаваплы башкаручысы;»;

әлеге карар белән расланган «Татарстан Республикасында электр автомобиль транспорты өчен заряд җыю инфраструктурасын үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында электр автомобиль транспорты өчен заряд җыю инфраструктурасын үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2022 ел, 7 июнь, 538 нче карары белән расланган «Татарстан Республикасында электр автомобиль транспорты өчен заряд җыю инфраструктурасын үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 ел, 13 декабрь, 1320 нче карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Бу карар 2024 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин